ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

2021 елның «16» декабре №1176

Лениногорск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау муниципаль адреслы программасына кертелгән йортлар исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексын, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 мартындагы 52-ТР номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау муниципаль адреслы программасына кертелгән йортлар исемлеген яңа редакциядә кушымта нигезендә расларга.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 7 сентябрендәге 1034/1 карары үз көчен югалткан дип санарга.

3.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (parvo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкче З.Г. Михайлова

Ф.М.Фәрхетдинов
5-76-90